| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 март Баулы шәһәре № 102

Закончалыкка һәм Татарстан
Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль
берәмлеге җирле үзидарә органнары
норматив хокукый актларына
үзгәрешләр кертү мониторингын
үткәрү турындагы нигезләмәне
раслау хакында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының закончалыкка һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтадагы Закончалыкка һәм Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары:

- үз нормалар билгеләү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган нигезләмәгә таянып эш итәргә;

- күрсәтелгән нигезләмәне үтәү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

- җаваплы затлар булып билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына, муниципаль норматив хокукый актларның законнарга, муниципаль берәмлекләр уставларына туры килүен системалы контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында, мониторинг үткәрүне тәэмин итә торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының http:bavly.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башлыгы урынбасарына һәм “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Баулы шәһәр Советы рәисе,
Баулы шәһәре Мэры

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре”
муниципаль берәмлеге
Советының 2019 елның
27.03 кабул ителгән 102
санлы карары белән
расланган

**Закончалыкка һәм Татарстан Республикасы**
**“Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары**
**норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү**
**мониторингын үткәрү турындагы**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Закончалыкка һәм Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингы (алда – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә) системалы, комплекслы, планлы эшне куздә тота. Аны җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра. Ул муниципаль актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны), үзгәртү яисә үз көчен югалткан дип тану (гамәлдән чыгару) өчен, мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләүдән гыйбарәт.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Җирле үзидарә органнары мониторинг үткәргәндә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге һәм Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең башка органнары белән хезмәттәшлек итәләр.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары:

- федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында, муниципаль актларны кабул итү, үзгәртү яки аларның үз көчен югалтуын тану ихтыяҗын ачыклау;

- муниципаль актларда коллизияләрне, каршылыкларны, пробелларны, хокукый җайга салуда кабатлануларны бетерү;

- җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

- муниципаль актларда коррупциячел факторларны ачыклау;

- муниципаль актларның яисә аларның аерым нигезләмәләренең (нормаларның) гамәлдә файдаланылмый торган (актуальлеген югалткан) яисә кулланырлык булмаган нигезләмәләрен ачыклау;

- хокукны куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген киметүче факторларны ачыклау;

- җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан муниципаль актларның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

- нормалар билгеләү процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг үз эченә түбәндәге үзгәрешләрне җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләүне ала:

- федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актларындагы үзгәрешләрне;

- Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актлардагы үзгәрешләрне;

- Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларындагы үзгәрешләрне;

- Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставындагы, муниципаль актлардагы үзгәрешләрне.

7. Мониторинг үткәрүгә нигез булып торалар:

- федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү;

- билгеле бер хокукый җайга салу өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

- прокуратура органнары мәгълүматы;

- массакүләм мәгълүмат чараларының муниципаль актларны камилләштерү кирәклеге яки алардагы кимчелекләр турында мәгълүматы;

- гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклаучы һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә алган:

- Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы үткәргән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

- муниципаль актларга билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар үткәргән коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

- җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләрнең, семинарларның, ачык тыңлауларның, җәмәгать фикер алышуларының һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары әлеге Нигезләмәнең 4нче пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнештә аларның компетенциясе мәсьәләләре буенча мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары кулланылырга

мөмкин.

9. Мониторинг түбәндәгеләргә анализ ясау аша башкарыла:

- әлеге Нигезләмәнең 6нчы пунктында күрсәтелгән актларга;

- федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларга дәгъва белдерү турындагы эшләр буенча суд актларына (суд практикасы);

- прокурор актлары.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән нормалар билгеләү эше нәтиҗәләрен фиксацияләү максатында муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла. Алар муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә төзелә.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (аларның операторлары белән килешүләр, контрактлар төзүгә бәйле мөмкинлекләр булганда), алар түбәндәгене тәэмин итә:

- «Гарант» мәгълүмат системасында контрольгә куелган норматив хокукый актларга үзгәрешләр керү турында мәгълүмат барлыкка килү;

- «Гарант» мәгълүмат системасындагы хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар барлыкка килү;

- «Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында муниципаль актларның закончалыкка туры килмәве турында мәгълүмат барлыкка килү.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатында башка мәгълүмат системалары сервислары файдаланыла ала.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны), үзгәртүне яки үз көчен югалтуын (гамәлдән чыгаруны) тану өчен мониторинг үткәргәндә, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән бергә түбәндәге критерийлар буенча муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

- кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

- муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) кирәклеген билгеләүче югарырык юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булу;

- муниципаль акт чыгарганда җирле үзидарә органы компетенциясенең чикләрен узмау;

- муниципаль актта коррупциячел факторлар булу;

- иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда һәр як исәпкә алынганлык;

- хокук нормалары коллизиясе;

- юридик-техник характердагы хаталар булу;

- муниципаль актны кулланганда аның нигезләмәләре мәгънәсен бозу;

- муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез

карарлар кабул итү, гамәлләр кылу (гамәл кылмау);

- норматив хокукый актларны куллану тәҗрибәсе булу;

- норматив хокукый актларны куллануның бердәм практикасы булмау;

- муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар (саны) һәм аларның эчтәлеге;

- муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турындагы үз көченә кергән суд актлары һәм аларны кабул итү нигезләре булу (саны).

13. Мониторинг нәтиҗәсендә муниципаль актларга үзгәрешләр кертүгә китерә торган федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр ачыкланганда, җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

- муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану турында, яңа муниципаль акт кабул итү турында муниципаль актларның проектларын эшләргә;

- муниципаль актларны югарырак юридик көчкә ия актларга туры китерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрергә.

14. Муниципаль актларны үзгәртү ихтыяҗы тудыручы федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика актын чыгарганнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокуратура мәгълүматы торса («Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль закон белән билгеләнгән срокларда карала торган прокурор йогынтысы актларыннан тыш), мониторинг 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче затка мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## 3. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт проектын эшләү һәм муниципаль акт кабул итү, әлеге нигезләмәнең 14нче пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгән вакыттан соң ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисап аеннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

- мониторинг үткәрүчеләр турында мәгълүмат;
- мониторинг үткәрү чоры турында мәгълүмат;
- хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасы, мониторинг үткәрү нигезләре.

16. 2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисапка (мәгълүматка) кертелергә мөмкин:

- хокукый җайга салудагы ачыкланган проблемалар турында мәгълүмат;
- муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актларны кабул итү, юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;
- тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабул ителгән муниципаль актлар законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрелә.

Мониторинг нәтиҗәсендә элгәре Регистрга кертелмәгән муниципаль актлар ачыкланса, алар да регистрга кертү өчен җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## 4. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый актлар чыгару эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук муниципаль актларны федераль һәм республика законнарына туры китерү өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җавап тоталар.

4.2. Мониторинг нәтиҗәләре буенча тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җирле үзидарә органнары җитәкчеләре закончалык нигезендә җавап тота.